СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.09.2019 с. Майдан № 58-271

**Мәйдан авыл җирлеге территориясендә**
**үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**
**җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты нигезендә, Мәйдан авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Мәйдан авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 11.09.2019 ел, № 57-268 карары, Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 11.09.2009 ел, № 28 карары нигезендә,

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Мәйдан авыл җирлеге**
**карар чыгарды:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Мәйдан авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза буласызмы?:

- Мәйдан авылына товар белән тәэмин итүче исәбенә вак таш сатып алу;

- Тәмте урманчылыгы бистәсендә һәм Ясная Звезда авылында су челтәрен ремонтлау. **ӘЙЕ** **ЮК»**

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Мәйдан авыл җирлеге**
**Башлыгы** **В.В.Михеев**